

# Туган төбәгем, мәктәбем, һөнәри эшчәнлегем

***Бөтенроссия “Туган тел”***
***мастер-класс бәйгесенең муниципаль турында катнашучы Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Мусина Гөлназ Шәриф кызы***

*Беренче бүлек.*

Туган җирем - Кама Тамагы районының искиткеч табигатьле Олы Кариле авылы. Әтием Шәриф, әнием Нәкыя мине инсафлы, игелекле, тырыш, саф күңелле бала итеп тәрбияләгәннәр. Авылыбызның чишмәләре суын эчеп, урман-болыннарындагы хуш исле җиләкләрен, шифалы үләннәрен ашап үскәнгәме, туган җирем күңелемә бик якын. Авылыма кайтсам, көчем арта, җаным чистарына.






Әтием – Халиков Шәриф Хәйретдин улы  “Бөек Октябрь революциясе”,  “Кызыл байрак”орденнары белән бүләкләнгән атаклы комбайнёр.7ел авылда мулла вазифасын башкарды. Инде вафат.


Әнием – Халикова Нәкыя Абдулла кызы  рус теле укытучысы, РСФСР мәгариф отличнигы.

Без-аларның биш кызыукытучылар.






Урта белемне мин Олы Кариле урта мәктәбендә алдым.
Укытучылар коллективы бик көчле иде.
Мин сыйныфтагы һәм мәктәптәге эшләргә теләп катнашучыларның берсе булдым.







Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтына укырга кердем.





Институтны тәмамлаганда, тормыш иптәшем белән гаилә корып җибәрдек. Безне Яшел Үзән районы Әйшә  урта мәктәбенә эшкә җибәрделәр. Без шушы авылда төпләнеп калдык. Улыбыз Наил һәм кызыбыз Миләүшә дөньяга килде.



Улым төзүче һөнәрен сайлады,өйләнде. Хатыны Светлана белән безгә ике онык бүләк иттеләр.



Кызым Миләүшә-дизайнер. Татар милли киемнәрен гадәти тормышка кертү теләге белән яна. Аның түбәтәйләрен бик күп хатын-кызлар киеп йөри.

